ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

“Муниципаль хокукый актның яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең тулы тексты тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган даими матбугат басмасында беренче тапкыр басылып чыгу аның рәсми басылып чыгуы дип санала.

Җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (игълан итү) өчен шулай ук челтәр басманы да файдаланырга мөмкин. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмада басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, аның күләмле графика һәм таблицалар булган кушымталары матбугат басмасында урнаштырылмаска да мөмкин.”;

б) 8 өлешкә “Муниципаль хокукый актларны” сүзләреннән соң “, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне” сүзләрен өстәргә;

2) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында”
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеге**

1) Азнакай муниципаль районы;
2) Әлмәт муниципаль районы;
3) Апас муниципаль районы;
4) Арча муниципаль районы;
5) Балтач муниципаль районы;
6) Бөгелмә муниципаль районы;
7) Буа муниципаль районы;
8) Югары Ослан муниципаль районы;
9) Биектау муниципаль районы;
10) Алабуга муниципаль районы;
11) Зәй муниципаль районы;
12) Зеленодольск муниципаль районы;
13) Кама Тамагы муниципаль районы;
14) Кукмара муниципаль районы;
15) Лаеш муниципаль районы;
16) Лениногорск муниципаль районы;
17) Менделеевск муниципаль районы;
18) Минзәлә муниципаль районы;
19) Түбән Кама муниципаль районы;
20) Нурлат муниципаль районы;
21) Яңа Чишмә муниципаль районы;
22) Питрәч муниципаль районы;
23) Балык Бистәсе муниципаль районы;
24) Саба муниципаль районы;
25) Тукай муниципаль районы;
26) Теләче муниципаль районы;
27) Чистай муниципаль районы;
28) Чаллы шәһәре.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 08 декабрь
№ 98-ТРЗ